# КАРАР

**16 ноябрь, 2020 ел** **№1**

**Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегенең Сәрдәүч авылында поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 16 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«I төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге затлар, туендыручысын югалткан күп балалы гаиләләрдән кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегенең Сәрдәүч авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Сәрдәүч авылында урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту һәм җәйге чорда территорияне чабу; ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Сәрдәүч авылында суүткәргечне ремонтлау, грунтны кулдан һәм экскаватор белән эшкәртү, торбаүткәргеч җәю (материаллар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру)?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

2020 елның 16 ноябренә торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны – 34 кеше.

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 30 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 22 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен җыенда катнашкан 22 кеше тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегенең Сәрдәүч авылындагы халык җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «I төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге затлар, күп балалы гаиләләр һәм туендыручысын югалткан гаиләләрдән кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегенең Сәрдәүч авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:
   - Сәрдәүч авылында урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту һәм җәйге чорда территорияне чабу; ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
   - Сәрдәүч авылында сууткәргечне ремонтлау, грунтны кулдан һәм экскаватор белән эшкәртү, торбаүткәргеч җәю (материаллар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру)?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип танырга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Ошторма-Юмья
авыл җирлеге башлыгы С.Г. Антонов